ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 апрель 2022ел № 1912

Башкарма комитетның 2022 елның 18 февралендәге 753 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча гражданнарны исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 18 февралендәге 753 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча гражданнарны исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында торак сатып алу өчен яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 1 пункты нигезендә, социаль түләүдән файдалану максатларында ярдәмче программада катнашу өчен, торак кредитлары, шул исәптән ипотека кредитлары яки торак урын сатып алуга торак заемнары буенча бурычның төп суммасын түләү һәм процентларны (әлеге кредитлар яки заемнар буенча йөкләмәләр үтәүне кичектергән өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан тыш) түләү өчен социаль түләүдән файдаланудан тыш, яшь гаилә даими теркәлү урыны буенча район хакимиятенә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) шәхесне раслаучы документ (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә таләп ителми);

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;

3) ярдәмче программаны тормышка ашыруда катнашу мөмкинлеге өчен яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану турында даими теркәлү урыны буенча район хакимиятенә гариза:

кәгазь документ формасында (административ регламентка 4 нче кушымта);

Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, административ регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле мәгълүматларны кертү юлы белән тутырыла);

4) гаиләнең һәр әгъзасының шәхесен раслаучы документ күчермәсе;

5) чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль расланган рус теленә тәрҗемәсе (булган очракта);

6) граждан хәле актларын теркәү органнары яки Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык (булган очракта);

7) торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булуны һәм түли алуны раслау өчен кирәкле документларны теркәп, форма буенча (административ регламентка 5 нче кушымта) планлаштырыла торган елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлегенә кертү турында гариза – ике нөсхәдә (гаризаның бер нөсхәсе, гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү датасын күрсәтеп, гариза бирүчегә кире кайтарыла);

8) «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, яшь гаилә әгъзаларының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары тарафыннан яшь гаилә әгъзалары турында персональ мәгълүматларны эшкәртүгә язмача ризалыгы;

9) гаиләнең кредит алырга мөмкинлек бирә торган керемнәре яисә социаль түләү күләменнән артып киткән өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен җитәрлек булган башка акчалары булуын раслый торган документ;

10) бирү датасын күрсәтеп, торак урынның гомуми мәйданы күрсәтелгән финанс-шәхси счет (оригинал);

11) бирү датасын күрсәтеп, йорт кенәгәсеннән өземтә (оригинал);

12) теркәлү урыны буенча биләнә торган торак урынга, шулай ук соңгы 5 елда милектәге башка торак урыннарга хокук билгели торган документларның күчермәләре (социаль наем шартнамәсе, приватизацияләү шартнамәсе, сату-алу шартнамәсе, бүләк итү шартнамәсе, милек хокукын теркәү турында таныклык яки күчемсез милекнең төп характеристикалары һәм күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклары турында Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә һ. б.), индивидуаль торак төзелеше объектларында яшәүчеләр өчен-әлеге объектка техник паспорт;

13) адресын, пропискага керү датасын, пропискадан төшү датасын, торак урынның гомуми мәйданын һәм соңгы биш елда яшәүчеләр санын күрсәтеп, элеккеге теркәлү урыннарыннан архив белешмәләре;

14) 2000 елның 1 гыйнварына булган мәгълүматлар буенча, гражданның барлык капиталь төзелеш объектларына теркәлгән хокуклары булуны (булмауны) раслаучы, теркәлгән күчемсез мөлкәте булу (булмау) турында Техник инвентаризацияләү бюросыннан белешмә – яшь гаиләнең барлык әгъзаларына, шул исәптән элеккеге яшәү урыннарыннан;

15) эш урыныннан оешма реквизитларын күрсәтеп, гражданның эш урыны,

аның вазыйфасы турында мәгълүматларны үз эченә алган, оешма җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан имзаланган һәм оешма мөһере белән расланган кәгазь формадагы яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эш бирүчедә булганда) белән имзаланган электрон документ формасындагы белешмә – яшь гаиләнең барлык әгъзаларына;

16) хезмәт эшчәнлеге турында кәгазь формада (хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, оешма җитәкчесе яки кадрлар бүлеге башлыгы имзасы белән расланган барлык битләр («хәзерге вакытка кадәр эшли» тамгасы белән) яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эш бирүчедә булганда) белән имзаланган электрон документ формасында мәгълүматлар – яшь гаиләнең барлык әгъзаларына;

17) узган һәм агымдагы еллар өчен хезмәт хакы турында белешмә (яшәү адресын күрсәтеп, 2-НДФЛ формасы буенча) – яшь гаиләнең барлык әгъзаларына;

18) стипендия (студентлар өчен), пособиеләр, пенсияләр, алиментлар (әгәр булса) алу турында белешмә;

19) яшь гаиләнең кертеме булуны раслаучы документлар (яшь гаиләнең бер әгъзасына рәсмиләштерелгән банк кертеме булуын раслаучы банк документы күчермәсе яисә яшь гаилә әгъзаларының тупланма счетларыннан өземтә) һәм (яки) кредитның максималь күләмен күрсәтеп, кредит оешмасының ир белән хатынга яисә аларның берсенә кредит (заем) бирү мөмкинлеге турында документ;

20) узган календарь ел һәм агымдагы елның узган хисап чоры өчен, салым инспекциясе тамгасы белән декларация (эшмәкәр өчен) яки йөкләтелгән керемгә түләүгә күчкән эшмәкәрләр өчен (соңгы алты айда) йөкләтелгән керемгә салым түләү турында таныклык.»;

2) 2.6.1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 7, 8 пунктчалар өстәргә:

«7) физик затны салым органында исәпкә кую турында мәгълүматлар (ИНН) – Россия Федераль салым хезмәте;

8) гаиләнең һәр балигъ булган әгъзасының индивидуаль шәхси счетының иминият номеры (СНИЛС) турында мәгълүматлар – Россия Федерациясе Пенсия фонды.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев